ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.05.2026 п.г.т.Алексеевское № 182

**Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 һәм 39.29 статьяларына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә,Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының норматив хокукый актын гамәлдәге законга туры китерү максатында,

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 22.04.2026 ел, № 154 карары белән расланган муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәреш һәм өстәмәләрне кертергә:

- 15 пунктны түбәндәге эчтәлекле 22 – 24 пунктчалар белән тулыландырырга:

«22) дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен, һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясындагы 1 пунктының 3.1 пунктчасында каралган очракта, хосусый милектәге элекке җир кишәрлеге мәйданы бер мең квадрат метрдан артыкка арта, моңа мондый яңадан бүлү территорияне ызанлауның расланган проекты яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлгәндә гамәлгә ашырыла, аларның әйләнеше «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» Федераль закон белән җайга салына торган очраклар керми;

23) Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясындагы 1 пунктының 3.1 пунктчасында каралган нигез буенча хосусый милектә булган җир кишәрлеген элек дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен күрсәтелгән нигез буенча яңадан бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән хосусый милектәге җир кишәрлеген яңадан бүлү карала;

24) әлеге Кодексның 39.28 статьясындагы 1 пунктының 3.1 пунктчасында каралган нигез буенча әлеге пунктның 23 пунктчасында күрсәтелгән җир

кишәрлегеннән бүленү яисә берләшү нәтиҗәсендә барлыкка килгән хосусый милектәге җир кишәрлеген яңадан бүлү күздә тотыла.».

- Административ регламентның 4 нче кушымтасында «Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 22-24 пунктлар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 22. | 1Б-8Б | Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен, һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясындагы 1 пунктының 3.1 пунктчасында каралган очракта, хосусый милектәге элекке җир кишәрлеге мәйданы бер мең квадрат метрдан артыкка арта, моңа мондый яңадан бүлү территорияне ызанлауның расланган проекты яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлгәндә гамәлгә ашырыла, аларның әйләнеше «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» Федераль закон белән җайга салына торган очраклар керми |
| 23. | 1Б-8Б | Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясындагы 1 пунктының 3.1 пунктчасында каралган нигез буенча хосусый милектә булган җир кишәрлеген элек дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен күрсәтелгән нигез буенча яңадан бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән хосусый милектәге җир кишәрлеген яңадан бүлү күздә тотыла |
| 24. | 1Б-8Б | Әлеге Кодексның 39.28 статьясындагы 1 пунктының 3.1 пунктчасында каралган нигез буенча әлеге пунктның 23 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлегеннән бүленү яисә берләшү нәтиҗәсендә барлыкка килгән хосусый милектәге җир кишәрлеген яңадан бүлү күздә тотыла |

2. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Э.Н.Павловага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **О.Н.Леденцов**